КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 27 ноябрь г.Казань № б-2581

Укучыларга тәрбия бирү системасын камилләштерү, югары әхлаклы, җаваплы, иҗади, инициативалы, компетентлы шәхес формалаштыруга һәм үстерүгә социаль-педагогик ярдәм күрсәтү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларга тәрбия бирүне үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 ел, 17 июнь, 443 нче карары белән расланган 2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларга тәрбия бирүне үстерү стратегиясен тормышка ашыру максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларга тәрбия бирүне үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 ел, 17 июнь, 443 нче карары белән расланган 2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларга тәрбия бирүне үстерү стратегиясен 2020 – 2022 елларда тормышка ашыру чаралары планын (алга таба – План) расларга.

2. Җаваплы башкаручылар булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

План чараларының үтәлешен тәэмин итәргә;

ел саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15енә кадәр Планны тормышка ашыру барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына кертергә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына бу боерыкның 2 пункты нигезендә алынган мәгълүматны гомумиләштерергә һәм ел саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 30ына кадәр аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларга тәрбия бирүне үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 ел, 17 июнь, 443 нче карары белән расланган 2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларга тәрбия бирүне үстерү стратегиясен 2020 – 2022 елларда тормышка ашыруның муниципаль чаралары планын эшләүне тәкъдим итәргә.

5. План чараларын финанслау тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында җаваплы башкаручылар булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин